ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 12 2024 г. № 1361

2025 елга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының авыл җирлекләрендә торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, 3.6 пунктларына таянып, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау хакында», торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында карар» нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елга Түбән Кама муниципаль районының авыл җирлекләрендә күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 11 процент күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Г. Парамоновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874